КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 октябрь г.Казань № 1223

Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе президиумы (штабы) тарафыннан 2023 елның 4 маендагы 25пр номерлы беркетмә белән расланган Гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казна кредитлары булган Россия Федерациясе субъектлары чараларын конкурс нигезендә хуплау методикасы буенча хупланган Татарстан Республикасы чаралары кысаларында гамәлгә ашырыла торган объектларның детальләштерелгән исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль казначылык тарафыннан федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча буш акчалары исәбеннән бюджет кредитлары бирү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәнең 12 (1) пунктына үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 31 мартындагы 525 номерлы карары белән расланган Федераль казначылык тарафыннан федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча буш акчалары исәбеннән бюджет кредитлары бирү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары М.Ш.Хөснуллин рәислегендәге Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе президиумының (штабының) читтән торып тавыш бирү турындагы 2023 елның 3 августындагы 44 номерлы беркетмәсе белән хупланган Татарстан Республикасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе президиумы (штабы) тарафыннан 2023 елның 4 маендагы 25пр номерлы беркетмә белән расланган Гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү

чыганагы махсус казна кредитлары булган Россия Федерациясе субъектлары чараларын конкурс нигезендә хуплау методикасы буенча хупланган Татарстан Республикасы чаралары кысаларында гамәлгә ашырыла торган объектларның детальләштерелгән исемлеген (алга таба – чаралар, объектларның детальләштерелгән исемлеге) 8 991 691,52 мең сум гомуми финанслау күләме белән расларга.

2. Чаралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы арасында төзелгән Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча буш акчалары исәбеннән бюджет кредитлары булган чараларын конкурс нигезендә сайлап алу кысаларында тормышка ашыру турындагы 2023 елның 11 сентябрендәге 1134-с номерлы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын – чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы булган федераль бюджетның бердәм счетының вакытлыча буш акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы бюджет кредиты рәвешендә бирелә торган акча белән баш эш итүче (алучы) итеп;

«Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесен – объектларның детальләштерелгән исемлеге нигезендә объектлар төзелешенең дәүләт заказчысы итеп.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

объектларның детальләштерелгән исемлеге нигезендә чараларны гамәлгә ашыруны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча чараларны гамәлгә ашыру турындагы хисапларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертүне;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән форма буенча Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатлар өчен махсус казначылык кредиты акчасын җибәрү турындагы хисапны махсус казначылык кредиты бурычларын тулысынча түләп бетергәнгә кадәр бирүне;

бу карарны, аңа кертелә торган үзгәрешләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм Федераль казначылыкка җибәрүне.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 25енә кадәр, түбәндәгеләрне кертүне тәэмин итәргә:

чараларны гамәлгә ашыру турындагы белешмәләрне Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына;

махсус казначылык кредиты бурычларын тулысынча түләп бетергәнгә кадәр Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән форма буенча Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга махсус казначылык кредиты акчасын җибәрү турындагы хисапны Федераль казначылыкка.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 3 октябрь, 1223 нче
карары белән расланды

# Россия Федерациясендә Төбәк үсеше буенча хөкүмәт комиссиясе президиумы (штабы) тарафыннан 2023 елның 4 маендагы 25пр номерлы беркетмә белән расланган Гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итү чыганагы махсус казна кредитлары булган Россия Федерациясе субъектлары чараларын конкурс нигезендә хуплау методикасы буенча хупланган Татарстан Республикасы чаралары кысаларында гамәлгә ашырыла торган объектларның детальләштерелгән исемлеге

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Инвестиция проекты исеме | Чара исеме | Инфраструктура объекты исеме/ объект адресы/ объектның проект куәте | Инфраструктура төре | Эшләр төрләре | Гамәлгә ашыру сроклары | | Финанслау чыганаклары | | | | Махсус казначылык кредиты чараларын үзләштерү планы | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | барысы | шул исәптән | | | шул исәптән | |
| | | | | | | | башлану датасы | тәмамлану датасы | | махсус казначылык кредиты | берләштерелгән төбәк бюджеты | бюджеттан тыш чыганаклар | 2023 ел | 2024 ел |
| | | | | | | | | | мең сум | мең сум | мең сум | мең сум | мең сум | мең сум |
| 1. | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы | Олы Зеленодольск | Олы Зеленодольск | Казан – Зеленодольск (Олы Зеленодольск) трассасы янындагы территорияләрне су белән тәэмин итү системасын төзү | Инженерлык-коммуналь | Төзелеш | 2023 | 2024 | 2 817 215,0 | 2 817 215,0 | 0,0 | 0,0 | 339 763,02 | 2 477 451,98 |
| | | | | «Салават күпере» торак районы өчен инженерлык һәм техник тәэмин итү челтәрләре төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәре. 6 нчы этап: Җитештерүчәнлекне тәүлеккә 32 мең куб метрга кадәр җиткереп, Васильево шәһәр тибындагы поселогында биологик чистарту корылмалары. Икенче чират | Инженерлык-коммуналь | Төзелеш | 2023 | 2024 | 2 553 931,0 | 2 553 931,0 | 0,0 | 0,0 | 252 724,73 | 2 301 206,27 |
| 2. | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы | Лаеш узелы | Лаеш узелы | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында Столбище авылы, Усад авылы, «Ак Барс» ТК, «Ак Барс Девелопмент» ТК районында су белән тәэмин итү системасын төзү | Инженерлык-коммуналь | Төзелеш | 2023 | 2024 | 2 400 306,06 | 2 400 306,06 | 0,0 | 0,0 | 437 482,53 | 1 962 823,53 |
| | | | | Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында «Иннополис» МИЗ мәйданчыгыннан «Березовая Роща» канализация насос станциясенә кадәр этемле хуҗалык-көнкүреш канализациясе төзү | Инженерлык-коммуналь | Төзелеш | 2023 | 2024 | 1 220 239,46 | 1 220 239,46 | 0,0 | 0,0 | 248 730,72 | 971 508,74 |
| Барысы | | | | | | | | | 8 991 691,52 | 8 991 691,52 | 0,0 | 0,0 | 1 278 701,0 | 7 712 990,52 |

_______________